Тататарстан Республикасы Нурлат шәһәре 15 нче номерлы “Алсу” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе.

# *Район этабында үткәрелгән “Туфрак – безне туендыручы” диган шөгыль конспекты.*

Тәрбияче:
Кәлимуллина Р.И.

Декабрь, 2012 ел.

# Туфрак – безне туендыручы.

(шөгыль)

**Максат:** Туфракның ничек барлыкка килүен, анда яшәүче микроорганизмнарның ролен, туфракның кайбер үзлекләрен ачып бирү, чагыштырып фикерләү сәләтен үстерү, кешеләрнең туфрак турында кайгыртуларын күрсәтү.
**Сүзлек:** туфрак, балчык, ком, уңдырышлы, суалчан, күбек, микроб.

**Материал:** "Тизрәк үс, агач" уенына атрибутлар,гөл, суалчан башлыгы; һәр балага: савыт белән су, салфетлар, ком, балчык, туфрак.

**Алдан башкарылган эш**: Бүлмә гөлләрен туфракка, балчыкка, комга утырту. Күзәтү һәм нәтиҗә ясау. Үсемлек кайда яхшырак үсә?

**Барышы.**

**Белмәмеш керә, күңелсез генә балалар белән исәнләшә.**
**Тәрбияче.** Балалар, Белмәмеш безгә кунакка килгән, тик нишләптер бик боек күренә. Нәрсә булды?

**Белмәмеш.** Менә гөл утырткан идем, шундый йомшак, әйбәт җиргә утырттым. Ә ул үсми, гел боегып утыра.

**Тәрбияче.** Ярар, Белмәмеш, борчылма, балалар сиңа ярдәм итми калмас, шулаймы? Әйдәгез, искә төшерик әле гөл белән үткәргән тәҗрибәне, гөл кайда яхшырак үсте? (Туфракта.)
**Белмәмеш.**Нәрсә соң ул **туфрак**? Мин гөл утырткан **туфрак** туфрак түгелмени? Монысы нәрсә? (Комга күрсәтә.)
**Балалар.** Монысы ком була.
**Бирем "Сүзләрне төзү"**. (**Ком, балчык, туфрак сүзләрен хәрефләдән ковралинда җыялар).**

**Тәрбиячеләр.** Дөрес, балалар. Туфрак, балчык һәм комның ничек бер-берсеннән аерылганын **тәҗрибә**ләр белән күрсәтик әле Белмәмешкә. Алдыгыздагы өч банкага да су салыгыз. Нәрсә күзәтәсез?

**Балалар.**Туфрак кара төскә керә, су үткәрә, балчык су үткәрми, ә ком аша су тиз үтә.

**Тәрбияче.** Юешләнгәч әвәләп буламы икән? (Балалар һәм Белмәмеш өчесен дә әвәләп карыйлар.) Нәрсә әйтерсез?

**Балалар.** Ком тарала, ә кызыл балчыкны әвәләп була. Туфракны әвәләп булмый.

**Тәрбияче.** Әйе, җирнең иң өске катламы – туфрак, ул комлы, балчыклы була. Иң әйбәте – кара туфрак, аңарда туклыклы матдәләр күп. Ә комда, кызыл балчыкта туклыклы матдәләр юк. Балалар, нишләп Белмәмешнең гөле үсмәгән? (Балалар җавабы:
-чөнки ул гөлне утырткан туфракта балчык күп булган;
-ул туфракта туклыклы матдәләр юк.)

**Белмәмеш.**Әйтәм аны, су сибәм- үсми, су балчыкка сеңми.

**Тәрбияче.** Ни өчен су өстә генә тора? (Балаларның җавабы:
-балчык суны сеңдермәгән, чөнки балчыкның кечкенә кисәкләре бер-берсенә нык ябышканнар.
**Тәрбияче.**Минем алда банкада туфрак. Өстенә су салам. Нәрсә күзәтәсез?

**Балалар.** Күбекләр чыга. (Ни өчен икәнен аңлаталар.)

**Тәрбияче.** Дөрес, димәк туфракта һава бар. Аны үсемлекләр сулый. Ә җир астында нәрсәләр яши соң?

**Балалар.** Сукыр тычкан, коңгызлар.

**Белмәмеш.** Беләм, беләм, суалчаннар.

**Тәрбияче.** Әйе, тагын микроорганизмнар (аңлата: микроскоп аша гына күренә торган организмнар - микроблар). Туфракта су бар. Аның белән үсемлекләр туена. Ни өчен сез гөлләргә су сибәсез? Сипмәсәң нәрсә була? (Балаларның җавабы:
-туфрак кибә, гөл корый һәм үлә.)

**Тәрбияче.** Туфракта яфраклардан барлыкка килгән черемә бар. Микроблар аларны үсемлекләр өчен кирәкле булган минераль тозларга әверелдерәләр.

**Тәрбияче.** Шәһәр паркларында коелган яфракларны җыеп яндыралар, сез аларга нәрсә диярсез? (Балалар җавабы:
-яфраклар астындагы бөҗәкләр үлә, файдалы матдәләр юкка чыга.) Әйе агачлар туклымлы матдәләрсез калалар.

**Тәрбияче.** Кайдан килеп чыккан соң безне туендыручы кара туфрак? Тыңлагыз**.(Слайдлар күрсәтелә).** Туфрак килеп чыгу өчен меңнәрче еллар кирәк. Бик күп еллар элек җир өстен уңдырышлы туфрак түгел, бары тик ташлар гына каплап алган. Җил, яңгыр, салкыннар, эсселекләрдән аларда ярыклар хасил булган, һәрвакыт ватылып торганнар. Ташлар бер-берсе белән ышкылып, ваклanып, ватылып торганнар, комга, балчыкка әверелгәннәр. Җилләр үсемлек орлыкларын алып килгәннәр. Алар комлы балчыкка

җайлашып тамыр җибәргән, яфраклары коелып, черемәгә әйләнгән. Еллар үтү белән нәзек кенә черемәле катлам барлыкка килгән. Аннан соң башка үсемлекләр үсеп чыккан һәм черемәгә әверелгән.

**Тәрбияче.** Ә туфракта яшәүче җан ияләре аларны черемәгә әйләндерергә ярдәм иткән. Балалар, кешеләр бакчада нәрсә эшлиләр соң?

**Балалар.** Җирне казыйлар, йомшарталар, су сибәләр.

**Белмәмеш.** Мин дә әнигә булышам.

**Тәрбияче.** Әйе, шулай эшләгәндә генә җир уңыш бирә. Мәкальләрне искә төшерик әле.

**Балалар.**-Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

- Эше барның ашы бар.
- Кем эшләми – шул ашамый.
- Эшләп үлмәссең, чирләп үләрсең.
- Ашаганда колагың селкенсен
  эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.
- Эштә булса батырлык,
  шунда була матурлык.
- Аннан-моннан эшләсәң яңадан эшләрсең.
- Эше барның ашы бар.
- Хезмәтнең тире ачы булса да,
  җимеше татлы була.
- Җир кара булса да икмәк ак.

**Тәрбияче.** Уңдырышлы туфракны сакларга кирәкме? Ничек? (-Агачлар, куаклар утыртырга кирәк.)

**Балалар.** Агач тамырлары белән туфрак ныгый. Алайса су юып, җил очыртып алып китәргә мөмкин.

**Тәрбияче.** Без нинди кагыйдәләрне белергә тиеш?

**Балалар.** – Туфракта яшәүче җан ияләрен сакларга.

-Паркларда, бакчалардагы коелган яфракларны яндырмаска, алар микроблар белән эшкәртелеп, туфракны минераль тозларга баеталар.

- Урманнарны кисәргә ярамый, бу елгаларны саегуга китерә, туфрак кибә.
- Агачларны күп итеп утыртырга кирәк.
- Урманнарны кисәргә ярамый, алар һаваны чистарта, туфракны ныгыта.

**Тәрбияче.** Бик дөрес аңлагансыз, балалар, Белмәмеш тә бүген күп нәрсә белгәндер. Әйдәгез, гөлен дә утыртырга ярдәм итик инде. (Бергәләп гөл утырталар.)

**<u>2 өлеш.</u>** Ә хәзер "Тизрәк үс, агач" дигән уен уйнап алыйк.
**Максат:** яфракның микроорганизмнар ярдәмендә эшкәртелеп, туфракка әверелүен һәм агачка үсәргә ярдәм итүен күрсәтү.
**Барышы.** Ике команда ярыша. Яннарында көзге агач яки яфраклар. Һәр командадан берәр кеше яфрак алып, каршыларындагы бәләкәй агачка йөгерә, яфракны "суалчан"га бирә ("суалчан" – бала). Ул аны агач төбенә куя. Кайсы команда тизрәк бетерә, шуның агачы тизрәк үсә.

## Шөгыльгә анализ.

Мин, Кәлимуллина Р.И. Бөгелмә пед.училищесының "Дошкольное воспитание" бүлеген 1993 нче елны тәмамладым, ул вакытта мин тимер юл балалар бакчасында эшли идем. 1996 нчы елны бу балалар бакчасы ябылу сәбәпле "Алсу" балалар бакчасына эшкә килдем. Менә шуннан бирле 16 ел инде "Алсу" балалар бакчасында эшлим. Пед.стаж 22 ел. 2007 нче елны 1нче категориягә ия булдым, быел 1 нче категорияне раслау. Безнең категорияне күтәрергә мөдиребез Фәридә Харисовна һәм өлкән тәрбияче Нәфисә Рифкатовна бик зур ярдәм күрсәтәләр. Алар һәрвакыт безне төрле конкурсларда, мастер-классларда катнашырга кирәклеген гел искәртеп , киңәшләрен биреп торалар.

Без, 2012 нче елның башыннан яңача эшләүне кертә башладык, быел яңа уку елына федераль дәүләт таләпләренә туры килгән методикалар кайтарттык, аларны кулланып эшли башладык:

-Комплексно-тематическое планирование по программе “От рождения до школы” под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой;

-Перспективное планирование планирование по программе “От рождения до школы” под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой;

-Комплексные занятия по программе “От рождения до школы” под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой;

-“Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы;

-“Балачак аланы китабы”;

-“Балачак – уйнап –көлеп үсәр чак” китабы;

-“Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы” (1,2 өлеш).

**Шөгыльнең темасы: Туфрак – безне туендыручы.**

**Максат:** Туфракның ничек барлыкка килүен, анда яшәүче микроорганизмнарның ролен, туфракның кайбер үзенчәлекләрен ачып бирү; балаларның тикшерү, тәҗрибә үткәрү эшчәнлеге нигезендә экологик фикер йөртү сәләтләрен үстерү, туфрак турындагы күзаллауларын киңәйтүне дәвам итү; балаларда барлык тереклек ияләренә карата шәфкатьлелек, табигатькә карата сак караш тәрбияләү, кешеләрнең туфрак турында кайгыртуларын күрсәтү, сөйләшү барышында мәкальләр кулланып, балаларның логик фикерләү сәләтен һәм сөйләм телен үстерү.

Бу шөгыль Федераль дәүләт таләпләре (ФДТ) буенча төрле укыту - тәрбия өлкәләрен интеграцияли (танып белү, сөйләм үстерү, грамотага өйрәтү, социализация, музыка). Шөгыль балаларның яшенә туры килә һәм 14 өлештән тора, бер өлеше икенче өлеше белән бәйләнеп, күчү сизелми. Тема тулысынча ачылды һәм максатка ирешелде. Балалар кызыксынып эшләделәр, арымадылар.

Бу шөгыльгә бик зур әзерлек эше алып барылды: ком, балчык һәм туфракны чагыштырдык, үзлекләрен билгеләдек (комга су салгач су тиз сеңә. Кызыл балчыкка су салгач су тиз генә сеңми, су өстә тора, аннары гына сеңә.Туфракка су салгач туфрак чем кара төскә керә, суны яхшы сеңдерә). Аларны әвәләп карадык, җәй көннәрендә әвәләп уйнаган вакытларны искә төшердек: юеш комнан әвәләгән әйберләр озак тормый, тарала. Шөгыльләрдә кызыл балчыктан кәҗәләр, курчаклар, өчпочмаклар, бавырсаклар әвәләдек. Аларны киптереп төсле буяуларга буядык. Аннан соң бүлмә гөлен комга, балчыкка һәм туфракка утыртып карадык: тәҗрибә ярдәмендә үсемлекнең (суган, бүлмә гөле) кайда яхшырак үсүен ачыкладык, тере табигать һәм тере булмаган табигать арасындагы бәйләнешне аңларга, мөстәкыйль фикер йөртә белү сәләтен үстерергә тырыштым.

Бөҗәкләр тормышы турында китаплар, рәсемнәр белән таныштык. Җәй көне яңгырдан соң суалчаннарны, кырмыскаларны күзәтүне искә төшердек. Уеннар, шигырьләр, мәкальләр өйрәндек, дидактик уеннар ясадык. Әти –әниләр һәм балалар

белән берлектә калдык әйберләрдән (бросовый материаллардан) поделкалар күргәзмәсе оештырдык.